| ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.06.2024 Казан шәһ. № 53-од

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2018 елның 12 апрелендәге 51-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2022 елның 3 октябрендәге 123-од номерлы, 2023 елның 1 матрындагы 23-од номерлы, 2023 елның 15 сентябрендәге 114-од номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.3 пунктының «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба - дәүләт хезмәткәрләре, Ветеринария идарәсе) «коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, коррупциягә каршы тору максатларында башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне, бурычларны үтәвен тәэмин итүдә (алга таба – хезмәт тәртибенә һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләр);»;

3.1 пунктын түбәндәге эчтәлектә бәян ителгән «е» пунктчасы белән тулыландырырга: «е) дәүләт хезмәткәренә, аның ихтыярыннан тормаган, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә комачаулый торган хәлләр барлыкка килү турында хәбәр итү.»;

3.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләр әлеге белдерүләрне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмәләр әзерләгән коррупцион һәм башка хокук бозуларны

Ветеринария идарәсенең кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан карала.»;

3.4.2 пунктындагы «3.1 пунктының «д» пунктчасында» сүзләрне «3.1 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләренә алыштырырга;

3.4.3 пунктында:

«а» пунктчасында «3.1 пунктының «д» пукнтчасында» сүзләрен «3.1 пунктның «д» һәм «е» пунктчасында» сүзләренә алыштырырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында, «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.15.2, 3.18 пунктлары яисә башка карар нигезендә карарларның берсен кабул итү өчен тәкъдимнәр.»;

3.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәләр, кагыйдә буларак, комиссиянең чираттагы (план буенча) утырышында карала.»;

3.8 пунктта «3.1 пунктының «б» пунктчасы» сүзләрен «3.1 пунктының «б» һәм «е» пунктчалары» сүзләренә алыштырырга;

3.8 пунктта «3.1 пунктының «б» пунктчасы» сүзләрен «3.1 пунктының «б» һәм «е» пунктчалары» сүзләренә алыштырырга;

Түбәндәге эчтәлекле 3.15.2 пункты белән тулыландырырга:

«3.15.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу һәм аның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин түгеллеге арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу һәм аның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин түгеллеге арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.»;

3.19 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча һәм моңа нигезләр булганда Комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.11 – 3.15.2 һәм 3.18 пунктларында каралганнан башка карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карар кабул итү нигезләре һәм мотивлары комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган дәүләт бюджет учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 30 ноябрендә 155-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган дәүләт бюджет учреждениеләренә Татарстан Республикасы

бюджетыннан башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүче затның (җыем түләүченең, иминият кертемнәрен түләүченең, салым агентының) салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү йөкләмәләрен үтәве турында белешмә формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча гариза бирү планлаштырылган айның беренче көненә бирелгән, салым түләүче затның (җыем түләүченең, иминият кертемнәрен түләүченең, салым агентының) салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү йөкләмәләрен үтәве турында салым органы белешмәсе;»;

$12^1$ пункты белән тулыландырырга:

«$12^1$. Ветеринария идарәсе әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән хисапларны күрсәтелгән хисаплар алдан хәбәр ителгән көннән алып 60 эш көненнән дә артмаган вакытта тикшерә.»;

$14^1$ пункты белән тулыландырырга:

«$14^1$. субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараның тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларга ирешү мониторингы (контроль нокта) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә уздырыла.».

3. Әлеге боерыкның 2 пунктындагы алтынчы һәм җиденче абзаслар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе А.Г.Хисаметдинов